Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 18 (31)

7 июнь 2012 ел

## • Ике авыз сүз

**КФУ ҺӘМ СТРАСБУРГ УНИВЕРСИТЕТЫНДА «ХЕМОИНФОРМАТИКА ҺӘМ МОЛЕКУЛЯР МОДЕЛЬЛӘШТЕРҮ» БЕЛГЕЧЛЕГЕ БУЕНЧА БЕРДӘМ МАГИСТРАТУРА АЧУ ПЛАНЛАШТЫРЫЛА.** Уку 2012 елның сентябрь аеннан башланыр дип көтелә. Магистратурага табигый фәннәр буенча белем алучы студентлар (бакалавр һәм белгечләр) кабул ителәчәк. Яңа белгечлек студентларга Европа университетлары дәрәҗәсендә магистр белеме алу; яңа дарулар, химик реакцияләрнең нәтиҗәләрен экспериментларсыз гына әйтеп бирә белү; химик күренешләрне модельләштерергә өйрәнү һәм аларны теоретик химия өлкәсеннән чыгып аңлата белү мөмкинлеге ача. Хемоинформатика өлкәсендәге белгечләр бөтендөнья буенча иң кирәклеләрдән санала. Шулай итеп, КФУ әлеге өлкәдә белгечләр әзерли торган дөньядагы өч университетның берсе булачак (Франциядәге Страсбург, АКШ ның Индиана университетлары инде бу өлкәдә эшли). Магистрларны кабул итү барышында, дипломдагы билгеләр һәм телдән тапшырылачак имтихан нәтиҗәләре исәпкә алына.

• • • •

КФУда **ГЕОФИЗИКЛАРГА КВАЛИФИКАЦИЯЛӘРЕН КҮТӘРҮ ӨЧЕН УНИКАЛЬ ПРОГРАММА ӘЗЕРЛӘНДЕ**. «ГЕОТЕК-холдинг» компаниясенең урта звенодагы 75 белгеч һәм җитәкчесе бездә 23 майдан 1 июньгә кадәр әзерлек курслары үтте. Укыту яңа программа буенча барды. Мондый типтагы квалификация күтәрү курслары һәм югары дәрәҗәдәге укыту программасы Россиядә беренче тапкыр оештырылды. Курсларда Sercel (Франция) компаниясеннән төп геофизик Дени Мужно, сейсморазведка өлкәсендә күп хезмәтләр авторы, геофизик Анатолий Череповский һәм геофизика өлкәсендә рус-инглиз, инглиз-рус сүзлекләре төзүче Сергей Вишняков та бар иде.

• • • •

2 июнь көнне **КФУга СИНГАПУРНЫҢ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНДӘГЕ ГАДӘТТӘН ТЫШ ҺӘМ ТУЛЫ ВӘКАЛӘТЛЕ ИЛЧЕСЕ ЛИМ КЕН ХУА ҺӘМ СИНГАПУР РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИКЕНЧЕ СӘРКАТИБЕ ХЕНЛИ ЧЕН КИЛДЕ**. Алар университет тарихы музее экспозицияләре белән танышты, тышкы элемтәләр буенча проректор Линар Латыйпов белән очрашу барышында, Сингапур һәм КФУ арасындагы территория һәм шәһәрләрне үстерү урбанистикасы, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен арттыру, педагогик белем бирү юнәлешләре буенча хезмәттәшлек итү турында сөйләште.

• • • •

Шул ук көнне **«ТАТАРСТАННЫҢ ЧИСТА УРМАННАРЫ ӨЧЕН» ИКЕНЧЕ РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ ТАБИГАТЬНЕ САКЛАУ АКЦИЯСЕ УЗДЫ**. КФУ студентлары да читтә калмады. Алар Биектау районы урманнарын чистартуга өлеш кертте. Сәгать ярым эчендә студентлар ял итүчеләр калдырган бик күп чүпчарны җыеп алды.

• • • •

Бүген КФУ ның Яр Чаллы филиалында сәяси фәннәр кафедрасы галим-мөгаллимнәре **ВУЗАРА «УРТАК ГРАЖДАНЛЫК ПОЗИЦИЯСЕ ФОРМАЛАШТЫРУ: ПРОБЛЕМАЛАР, ЗАМАНЧА ТОРЫШ, ПЕРСПЕКТИВАЛАР» ТЕМАСЫНА «ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ» УЗДЫРА**. Чарада университет галимнәре, укытучылар, ТР Фәннәр академиясе әгъзалары да катнаша.

• • • •

Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтының IV курс студентлары **ЭНГЕЛЬ СӘЙФЕТДИНОВ ҺӘМ ГҮЗӘЛ МУЛЛАГАЛИЕВА**, барлык конкурс этапларын үтеп, «Сигез төркеме» һәм «Егерме төркеме» **ЯШЬЛӘР САММИТЫ КАТНАШУЧЫЛАРЫ БУЛДЫ**. Алар Россия делегациясе составында АКШ ның Вашингтон шәһәрендә 2 июньдә башланган Саммитта катнаша.

• • • •

3 июнь көнне **ЯР ЧАЛЛЫГА ЭЧКЕ СӘЯСӘТ БУЕНЧА РОССИЯ ПРЕЗИДЕНТЫ ИДАРӘСЕ ҖИТӘКЧЕСЕ ОЛЕГ МОРОЗОВ КИЛДЕ**. Мэриядә шәһәр башлыгы, Шәһәр советы депутатлары катнашында узган очрашуда Олег Морозов, традиция буенча, студентларга стипендияләр тапшырды. Әлеге стипендиягә КФУ ның Яр Чаллы филиалы юридик факультетының III курс студенты Илдар Гәрәев һәм Кама дәүләт инженерия-икътисад академиясе студенты Евгений Рябов ия булды.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Әмир Фазлыйәхмәтов фотосы

# Йөз елга бер тапкыр

**Динара ӘХМӘТОВА**,
хәбәрче

Кичә, ягъни 6 июнь көнне планетабызда уникаль күренешне күзәтә алдык. Казан федераль университеты галимнәре безгә Кояш дискы буенча Венера планетасының хәрәкәт итүен күрү мөмкинлеге тудырды.

2012 ел безне үзенең күп кенә сәер вакыйгалары белән шаккатырып тора. Кышы – кыш төсле, язы яз төсле түгел, дигәндәй... Җәй бераз үзенә охшарга уйлый, ахры. Шулай да җәйнең беренче аена аяк басуга, без галәмдәге уникаль астрономик күренешне күзәтә алдык. Венера планетасының Кояш дискы буенча әйләнеп чыгуы – 100 елга бер парлап була торган хәл, чираттагысы 2117 елга туры киләчәк.

«Билгеле булганча, җиргә иң якын торган Венера планетасы орбитасы Җир белән Кояш арасында урнашкан. Шуңа күрә һәр 583,93 җир тәүлеге саен бу планета Җир белән Кояш арасына керә. Әлеге моментта Венера безгә дискта Кояштан 30 тапкыр кечкенәрәк кара түгәрәк кебек күренә. Әгәр Венера Кояш тирәли җир кебек шул ук тигезлектә әйләнсә, без аны һәр ел саен диярлек күзәтә алыр идек. Ләкин Венера орбитасы җир орбитасына 3,4° авышкан, шул сәбәпле планета кояш дискыннан я югарырак, я түбәнрәк әйләнә. Шуңа күрә Венера (Меркурий) планетасының Кояш дискы буенча узуы иң сирәк күренешләр рәтенә кертелә», – дип мәгълүмат бирә астрономия һәм космик геодезия кафедрасының өлкән фәнни хезмәткәре, Физика институты доценты Алмаз Галеев.

Мондый күренешләрнең булуы XVII гасырда Иоганн Кеплер тарафыннан ачыклана, ләкин беренче тапкыр аны 1639 елның 4 декабрендә инглиз астрономы Иеремия Хоррокс күзәтә. Ул турыдан-туры Венераның диаметрын үлчи. Мондый күренешләр шулай ук Кояш белән башка планеталарның арасын төгәл билгеләргә дә ярдәм итә. Алга таба Венераның әлеге хәрәкәте 1761 һәм 1769 елларның июнендә, 1874 һәм 1882 елның декабрендә була. 1761 елда бөек галим Михайло Ломоносов күзәткәндә, әлеге планетаның атмосферасын ача.

Казанда бу парлы күренешнең беренчесе 8 ел элек, 2004 елның 8 июнендә күзәтелә. Казан университетының астрономия кафедрасы хезмәткәрләре махсус тикшерү эшләре алып баралар, шулай ук телескоп ярдәмендә башкаларга да күрсәтәләр. Быел да әлеге традиция сакланды, Казан федераль университетының астрономия һәм космик геодезия кафедрасы һәм «Лира» астрономик клубы кичә иртәнге биштән башлап теләге булган һәркемгә парлы күренешнең икенчесен (Венера планетасын) күрү мөмкинлеге тудырды. 7 сәгать дәвамында сулдан уңга хәрәкәт итә торган Венераны без Кояш чыккач кына күрә алдык. Кояшка туры карарга ярамый, чөнки күзгә зур зыян килергә мөмкин. Шулай ук махсус утны фильтрлый торган пыяла җиһаз ярдәмендә дә күзәтеп була иде. Заманча технологияләр ярдәмендә күренешне интернет аша туры эфирда да күрсәттеләр. Ләкин үз күзләрең белән күрүгә ни җитә?

Чараны оештыручылар: «Халык бик кызыксына, төрле сораулар бирә. Сәгать биштән үк килә башладылар, эшкә киткәнче бирегә ашыгалар», – ди. Лаеклы ялдагы ханым Галина Фомина 6 яшьлек оныгы Максим белән килгән һәм кафедра хезмәткәрләренә рәхмәт сүзләре җиткерде. Студентлар да, сессия вакыты булуга карамастан, биредә мәш киләләр. «Кем белә, бәлки имтиханда да бәхет елмаер?! Мондый вакыйга көн саен булып тормый бит», – ди алар.

Ясаласы ачышлар ясалган инде, дияргә ашыкмыйк. Бу көнне күпләр үзләре өчен тагын яңа мәгълүматлар алды. Йөз елга бер була торган парлы күренешне үз күзләрең белән күрү – үзе үк ачыш түгелмени?

## • Халыкара рус теле көне

# Пушкинны бары Фукс... саклый

**Динара ЗИННӘТОВА**,
журналистика һәм социология факультеты студенты

6 июнь көнне бөек рус шагыйре, драматургы һәм прозаигы Александр Сергеевич Пушкинның тууына 213 ел тула. Әдип хәзерге рус теленең формалашуына зур өлеш кертүчеләрнең берсе буларак та билгеле.

**Ахыры 2нче биттә.**



● Тәңгә - мунча, җаңга - юк

# «Кая кертим, улым?..»

**Ленар ХАММАТОВ,**
татар филологиясе бүлеге студенты

Арып-талып укып кайткач, менә хәзер авылга кайтып китәм генә дигәндә, тулай торакның коменданты Рузалия Миннәхмәт кызы шалтыратты. Тулай торакта яшәүче татар филологиясе бүлеге студентлары кайсысы бюджет, кайсысы түләп укуда, шуны белергә кушканнар.

Гадәти эш булгач, беркайчан да уйлап та караган юк иде, шуңа, белер өчен, деканатка шалтыратырга туры килде. Әлбәттә, мин көткән җавап формасы булмады, ник дигәндә, мин шуның кадәр бюджет, шуның кадәр түләп укучы дигән сүз көткән идем. Ә миңа: «Бездә барлык студентлар да бары тик бюджет нигезендә генә укый», – дигән җавап кайтардылар.

Шуннан соң күңелемә бер мизгелгә караңгылык иңде, башка әллә нинди уйлар килә башлады. Ничек инде ул алай, калган бүлекләргә кеше ашкынып тора, инде бюджет урыннары беткәч, нәкъ менә шунда укыйсым килә, диеп, күпме күләмдә акча түгеп укырга кирә, ә монда урын беткәч, ярар, бетмәгәндер әле укыр җир, дип китеп баралармы?.. Икътисадчы, юрист кебек һөнәрләр 40-60 мең түләп укуны сорый.

Үземнең сыйныфташларыма да әти-әнисенең: «Улым, әгәр унберне әйбәт кенә тәмамласаң, бу үгезләр синә инде, Алла бирсә, менә «экономист», «юрист» (аерма юк кебек тә, ник дигәндә, алар өчен кайчакта икесенең берсенә керсен генә, исемнәре күп яңгырый, акча күп эшләр, телевизорда да аларны гына күрсәтәләр бит!) булырсың, зур урында утырырсың», – дип әйткәннәрен ишетергә туры килде... XI сыйныфта укыганда, бер язучыга үземнең татфакка укырга керәчәгемне әйткәч, ул минем теләкне көчәйткән сүзләр әйтте: «Кем булырга телисең, шул булып була, кая телисең, шунда кереп була, ләкин, иң беренче чиратта, үз тарихыңны, әдәбиятыңны, милли үзенчәлекләреңне белү зарурдыр, биш ел үтә дә китә ул, аннан соң экономист буласыңмы, юрист буласыңмы, анысы синең эш». Минем өчен көн саен бу сүзләрнең яңа мәгънәләре ачыла. Дөрестән дә, син гади юрист булып, кемне якламакчы буласың соң, икътисадчы булып, депутат булып, кемнең мәнфәгатьләрен якламакчы буласың?.. Аңлар өчен, кечкенә баланы мисалга китерәсем килә: әгәр дә әнисе ипи кискәнне күреп, ялтырап торган пычакка кызыгып, аны сораса, ана кеше яшь балага аны бирерме икән, әллә киселер, дип куркып, бирмәскә дигән нәтиҗәгә килер микән? Үсүен көтәрме?.. Әлбәттә, икенчесен сайлаячак... Монда да шул ук мәсьәлә, башта яшәр өчен нигез салырга, үзеңнең халкың турында белем, гыйлем алып чыгарга кирәк.

80-90 ел гомереңнең 5 елын, нибары 5 елын нигез салу өчен җәлләмәсәң, бәлки, син дә, дустым, акча эшләр өчен программалаштырылган робот түгел, ә үз милләтеңә, үз телеңә хезмәт итүче шәхес булыр идең...

● Бездә кунак бар

# Бөтен кореецне - Казанга?

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

5 июль көнне университетыбызга Корея кунагы – Пусан милли университетының полимер һәм машина төзелеше кафедрасы мөдире, профессор Иль Ким килде. Аның максаты – Казан федераль университеты белән танышу, студентлар белән аралашу һәм уку йортлары арасында бәйләнешләр урнаштыру иде.


Әмир Фазлыйәхмәтов фотосы

Кунак университетыбыз, аның тарихы музее белән танышып чыкканнан соң, тәэсирләре белән уртаклашып: «Казан шәһәре заман белән берлектә үсеш кичереп алга киткән дәвердә традицияләрен, милли сыйфатларын җуймыйча саклап кала алган. Искиткеч матур шәһәр! Корея кайтканнан соң, бөтен кешегә дә монда килергә тәкъдим итәчәкмен», – диде.

Алга таба профессор университетлар арасында килешүгә кул куелачагын әйтте. Әлеге килешү нәтиҗәсендә Казан федераль университеты белән Пусан милли университеты арасында тыгыз элемтәләр урнаштыру һәм студентлар алмашу практикасыннан да файдалану күздә тотыла.

Пусан милли университетына килгәндә, ул хәзерге вакытта иң танылган һәм алга киткән уку йортларының берсе булып санала. Аңа 1946 елның маенда нигез салынган. Беренче адымнарын ул икееллык милли университет булып башлап җибәрсә, 1953 елдан инде дүртьеллык югары уку йорты булып оеша. Хәзерге көндә анда 17 мең студент белем ала, күбесе тулай торак белән тәэмин ителгән. Студентлар өчен барлык уңайлыклар да тудырылган: йөзләп фәнни түгәрәк эшли, бүтән уку йортлары белән тәҗрибә алмашу программалары да бик актив кулланыла, чит телләрне өйрәнү, имтиханнарга әзерләнү өчен махсус шартлар бар. Хәзерге вакытта Пусан милли университеты үз эченә 14 көллият һәм 20 төрле һөнәри мәктәпне берләштерә.

● Халыкара рус теле көне

# Пушкинны бары Фукс ... саклый

**Башы 1нче биттә.**

Бу көнне бөек шагыйребезнең туган көнен генә түгел, ә Халыкара рус теле көнен дә билгеләп үтәбез. Әлеге чарадан Казан федераль университеты да читтә калмый. Филология һәм сәнгать институтында тантаналы рәвештә Гыйльми совет утырышы узды. Танылган филолог-галимнәр, рус теле тарихы һәм славян теленә кереш кафедрасы профессорлары Татьяна Николаева «А.С.Пушкин һәм рус теле» темасына һәм Геннадий Николаевның «Рус операларында Пушкин сюжетлары» дигән лекцияләре тыңланды.

Шулай ук Кытай, Төркия, Вьетнамнан килеп укучы студентлар өчен блиц-сораштыру да оештырылды. Чит ил студентлары «Мин ни өчен рус телен өйрәнәм? Дөньяда рус теленең әһәмияте нидән гыйбарәт? Минем өчен Пушкин исеме нәрсә турында сөйли?» кебек сорауларга җавап бирде.

Үз вакытында Александр Пушкин, Емельян Пугачёвка бәйле истәлекләр җыю максаты белән, Идел буе һәм Урал буйлап сәяхәт итә, ә 1833 елның 5 сентябрендә Казанда туктала. Ике көннән Пушкин Казаннан хатынына мондыйрак эчтәлекле хат юллый: «Монда мин героемның чордашлары – хәзерге картлар белән аралаштым, шәһәр тирәләрен урадым, сугыш барган урыннарны карадым, сораштырдым, яздым һәм бу якка баруымнан бик канәгать калдым». Бирeдә шагыйрь тарафыннан җыелган күп кенә мәгълүмат соңыннан «Капитанская дочка» романына керә.

Казанда Александр Сергеевич кунакханәдә яши. Әлеге йорт хәзерге Рәхмәтуллин урамында урнашкан була, күп еллар дәверендә бу бина тарихи архитектура истәлеге исеме астында саклана, 2010 елда исә янгын нәтиҗәсендә юкка чыга. Тарих белгече Леонид Девятых сүзләренә караганда, Казанда Пушкинга бәйле тарихи урыннар элек бишкә якын булган: Сукно бистәсендә Горлов кабагы, хәзерге Милли китапханәгә кушылып торган сәүдәгәр Крупенников йорты, Профсоюз урамындагы Перцов йорты, Рәхмәтуллин урамындагы кунакханә һәм Фукс йорты. Бүген әлеге исемлектән соңгысы – Фукс йорты гына сакланып калган.

Гомумән, Казанда бөек рус шагыйре исеме белән бәйле урыннар – башкалабызның үзәгендәге Пушкин урамы һәм Опера-балет театры янында урнашкан һәйкәл. Үзәктәге урамга Пушкин исеме 1899 елда, әдипнең тууына 100 ел тулу уңаеннан бирелә. Һәйкәл дә шул ук елны куела.

Александр Сергеевич Пушкин әсәрләре белән таныш булмаган кеше бүген, мөгаен, юктыр. Һәрберебез диярлек бала вакыттан ук аның әкиятләрен укып, үсмер чагында тарихи әсәрләре белән мавыгып үскән. Безгә тормыш сабагы, тәрбия биргән бөек әдипләребезгә булган хөрмәтебезне югалтмыйча, күпгасырлы тарихка бәйле урыннарны саклау – безнең бурычыбыз.

● Бәйге

# Көрәккә дә, акылга да эш бар

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче

Татар телен үстерү, аның киләчәген кайгырту буенча Казан Мэриясенең эшләгән эшләре күп. Шундыйларның берсе – «Татар теленең үсеше һәм кулланылышы» фәнни-эзләнү эшләре конкурсына нәтиҗәләр ясау 5 июнь көнне Мэриянең утырышлар залында үтте.

«Конкурс быел җиденче тапкыр үткәрелә. Елдан-ел көчлерәк студентлар, тирәнрәк эчтәлекле эшләр килә, – дип искәртте оештыручыларның берсе, Казан шәһәре Балалар һәм яшьләр эшләре бшкарма комитеты рәисе урынбасары И.Шакиров. – Шушы проект аша Казанның киләчәген татар милләте белән бәйләү күздә тотыла, алга таба бу ачык конкурс булып калыр», – диде ул, сүзен йомгаклап.


Артур Зиннуров фотосы

Биредә мәркәзебезнең төрле вуз, ссузларында укучы студентлар катнашты. Аларның һәрберсе татар телен үстерү, заманга яраклаштырып куллану, киләчәген кайгыртуга багышланган фәнни, тирән эчтәлекле чыгышлар ясады. Бирегә килүчеләр «Казан Кремленә экскурсия», «Идел Болгарстанында медицина», «Көрәшкә кагылышлы терминнарның рус, инглиз телләренә тәрҗемәсе», «Татар телен укытуда заманча технологияләр» кебек кызыклы чыгышлар, презентацияләр, методик ярдәмлекләр белән таныштылар. Аеруча 2013 елгы Универсиада белән татар теленең бәйләнешенә кагылышлы хезмәтләр игътибарга лаек иде. Әлеге конкурста безнең студентларыбыз да актив катнашучылар һәм, әлбәттә инде, җиңүчеләр булды. «Татар теленең үсеше һәм кулланылышы» фәнни-эзләнү эшләре конкурсының быелгы төп җиңүчесе дип Филология һәм сәнгать институтының татар филологиясе бүлеге студенты Раилә Бикчәнтәева билгеләнде.

«Мин быелгы эшләрдән аеруча да канәгать. Берсен дә начар дип төшереп калдырып та, тәнкыйтьләп тә булмый. Студентларыбыз елдан-ел без – жюри әгъзаларын шаккатыра, куандыра. Аларның эшләрен балалар бакчалары, мәктәп, югары уку йортларында укыту процессында кулланып та, киләчәктә хәтта кандидатлык диссертацияләре итеп үстереп тә булачак», – ди жюри рәисе Флёра Ганиева. Чыннан да, чыгышларны тыңлаган күпме кеше татар халкы, аның тарихы, сәнгате, гореф-гадәтләре, киләчәге турында уйланды, үзе өчен нәтиҗәләр ясады. Конкурсның кунагы, күренекле татар халык шагыйре Ренат Харис сүзләре белән әйтсәк, әлеге конкурска һаман да алга барырга, киңәергә, тирәнәергә кирәк. Безнең милләтебез тарихын өйрәнү өчен, әле көрәккә дә, акылга да эш җитәрлек. Тырышырга, эзләнергә!..

● Мәсьәләгә бер караш

# Имтиханга - бәйрәмгә!

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Бүген мөгаллим өчен укучыларының психологик халәтен җайга салу һәм аралашу процессының нәтиҗәлелеген арттыру аеруча мөһим. Дидактик максатларда кулланыла торган психологик алымнардан да файдалана белү кирәк.

Яшьләрдә агрессия көчле. Мәктәп һәм югары уку йортларындагы имтиханнар чорында шәкертләрнең хәлен аңлап, сезгә заманча нейролингвистик программалаштыру алымнарын кулланып карарга киңәш итәбез. Алар:



● аутоген күнекмә – үз-үзеңне психологик яктан төзәтү, үзеңне ышандыру, психиканы үзең көйләү һ.б. Әлеге метод хис-кичерешләр белән идарә итәргә, көч һәм эшкә сәләт тупларга, киеренкелекне җиңәргә ярдәм итә;

● арттерапия – сәнгать чаралары терапиясе кеше кичерешләрен, авырлык һәм каршылыкларны образ сурәтендә күз алдына китерүгә нигезләнә. Ул сынлы сәнгатьнең ирекле темага рәсем ясау, әвәләү, материалларны сайлап алып, аппликация эшләү, танылган әсәрләрне репродукцияләү кебек төрләренә һәм сәнгать әсәрләрен анализлау, укытучы белән шәкертләрнең бергәләп иҗат итүләренә нигезләнә.

● бию психотерапиясе – биюне, бию хәрәкәтләрен эмоциональ бушану, киеренкелекне бетерү максатында куллану. Мәсәлән, барлык яшьтәге укучы-студентлар өчен тиешле физкультминут урынына әлеге ысулны файдаланырга мөмкин;

● имаготерапия – баланың шәхес буларак үсеш процессын тәртипкә салу өчен, төрле уеннар куллану;

● библиотерапия – китап уку ярдәмендә хисләргә басым ясау. Әсәр геройлары белән бергә укучылар билгеле бер эмоциональ халәт кичерә, катлаулы хәлләрдән чыгу юлларын эзли. Бу аларның социаль компетентлылыгын киңәйтә, тормыш нормаларын үзләштерергә ярдәм итә;

● моритатерапия – әйләнә-тирәдәгеләрдә үзең турында яхшы фикер тудырырга этәргән хәлгә кую;

● логотерапия – мәгънә белән дәвалау кешенең үз-үзен тотышын камилләштерүгә китергән төп көч – яшәү мәгънәсен эзләү, аны тормышка ашыру дигән фикергә нигезләнә.

Әлбәттә, психотерапевтик сеанслар үткәрү укытучының функцияләре һәм тиешле вазифаларына керми. Шулай да алдарак санап үткән алымнарның кайбер элементларын БДИга әзерлек вакытында куллану урынлы булыр иде. Мондый эшләрне психолог белән уртак планлаштырып тормышка ашыру тагын да нәтиҗәле булачак.

● Студент колагына

# Шпаргалкалар да «үсә»!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Һәрбер кешенең дә үз гомерендә – мәктәптә булсынмы ул, югары уку йортымы – шпаргалкалардан файдаланганы бар.

Бу һич тә белемсезлек, үз-үзенә ышанмаучанлык билгесе түгел, чөнки шпаргалкаларны язу һәм, иң мөһиме, аны вакытында укытучыга сиздермичә генә файдалана белү – үзе бик зур осталык сорый һәм бу эш һәркемнең дә кулыннан килми. Әмма, беркемгә дә сер түгел – студент халкы бик тырыш һәм фантазиягә бай, бу мәсьәләдә бигрәк тә. Алар әлеге процесска бик иҗади, креатив якын киләләр. «Бомба», «гармошка»лар белән беррәттән, күп кенә башка, гадәти булмаганнары да бар.

Шпаргалкаларның тарихы бик еракларга барып тоташа. Иң борынгы шпаргалкаларның берсе инде XIV гасырда ук Кытайда уйлап табылган булган. Хәзерге вакытта ул Конфуций храмында урнашкан император көллиятенең музеенда экспонат рәвешендә саклана. Дөньяда иң оригиналь шпаргалкалар тупланган музейлар булуы да билгеле. Кемнеңдер чупа-чупс кәнфитеннән ясарга башы җиткән, ә кемдер гадәти карандашка физикадан унлап мәсьәләне язып тутыра алган!

Замана үзгәрү белән бергә, шпаргалкалар да камилләшәләр – «техникалаша» баралар. Хәзерге көндә бигрәк тә электрон шпаргалкалар популяр. Кечкенә кәгазь битләренә вак итеп язылганнары урынына телефон, интернет ярдәмгә килә. Алай мәшәкатьләнеп, төннәр буе язып утырырга да кирәк түгел: телефонында интернет тоташкан булса, «5»лене кесәңдә дип уйла. Һичьюгы кирәкле материалыңны компьютерда җыеп яисә интернеттан алып, шулай ук телефонга кертеп була. Әгәр телефоның «текә» икән, комплектында «Hand-free» наушниклары булса, шулай ук сессия бик җиңел тоелачак. Инде заман таләпләренә туры килә торган, иң алдынгы шпаргалкалар рәтенә кергән җиһаз – ул кесә компьютеры (PocketPC). Өстенлеге бик кечкенә булудан гыйбарәт, яшерергә җиңел һәм укытучыларның күбесе аның турында белеп бетермиләр.



Менә шулай: дөньялар үзгәрү белән, тормышлар да җиңеләя кебек. Әмма бу алгарышның кире ягы да юк микән? Күп еллар буе шпаргалка әзерләү ул кечкенә битләргә язуны аңлаткан. Мондый төр язу имтихан, контроль эшләр вакытында аннан күчерү дигән сүз түгел. Шпаргалканы әзерләү процессында кеше материалны укый, эшкәртә һәм шуннан соң иң кирәкле, мөһим моментларны язып, теркәп бара. Бу вакытта күз хәтере белән бергә кул моторикасы да эшкә җигелә, кул язган сүзләрне тел дә үзеннән үзе кабатларга мәҗбүр була. Шул рәвешле, шпаргалканы кулланса-кулланмаса да кеше инде материалны кабатлаган була. Ә заманча шпаргалкалар бу процессны юкка чыгара түгелме соң?

Хәзер студентларның, чыгарылыш сыйныф укучыларының «урак өсте» – имтиханнарвакытыҗитте һәм шпаргалка ясаргамы-юкмы икәнен һәркем үзе хәл итә. Ничек кенә булмасын, аларга уңышлар һәм, нинди генә шпаргалка ясасалар да, оста итеп, бүтәннәргә сиздермичә генә файдалана алуларын телибез.

● Белем баскычлары

# Өлкән студентлар

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

4-6 июнь көннәрендә «Өлкәннәргә белем бирү – 2012» дип аталган ЮНЕСКО акциясе узды.

Россиядә беренче мәртәбә – 2000 елда, Татарстанда 2002 елдан үткәрелә башлаган әлеге чара күркәм традициягә әверелде. Казан университеты Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге дә әлеге чарадан читтә калмады.

Атналык «Гомер буе белем эстәү: идеяләр, концепцияләр, форма, метод, технологияләр төрлелеге» темасы астында узган чара көндәшлеккә сәләтне югалтмау һәм тормыш сыйфатын күтәрү өчен, инновацион процесска керү; өлкәннәргә белем бирү өлкәсендә үзебезнең һәм чит ил тәҗрибәләренең интеграциясе; акциядә катнашучыларның квалификациясен күтәрү максатын тормышка ашырды.

Үзәктә узган чарада актуаль һәм кызыклы темаларга дискуссия, тренинг, мастер-класс, презентация, «түгәрәк өстәл», ачык дәрес, лекцияләр оештырылды. Мактаулы кунакларның берсе – Санкт-Петербургтан Гуманитар белем бирү институтының дәүләт һәм муниципаль идарә итү кафедрасы профессоры, икътисад фәннәре докторы Нина Литвинова мондый чараларның кирәк булуын, киләчәктә дә бу эшчәнлекне бергә дәвам итәргә иде, дигән теләген белдерде.

● Кечкенә галимнәр

# «Соберите книжки»!

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Икенче курста укыганда «Сүз ясалышы» курсыннан лекциягә кереп утыргач, аудиториягә кояш кебек балкып Чулпан апа килеп керде. Бердән, аның йөзе шулкадәр көләч, икенчедән, тавышы иркәле торган иде. Студент елларындагы кызыклы хатирәләре белән уртаклашуын үтенгәч, ул берсүзсез ризалашты. Шулай итеп, бүгенге кунагыбыз – профессор, киң эрудицияле галим, студентларның яраткан укытучысы Чулпан Мөхәррәм кызы Харисова.





*«Студент еллары һәртөрле истәлекле вакыйгаларга бай бит инде ул. Шулар арасында берсен, һәрвакыт сессия вакыты җитеп,зачеткаларны күргәч, көлемсерәп, искә алам.*

*...13 нче август иде ул. Беренче курс булгандырмы,икенчедерме, инде безнең семестр азагында «Возрастная психология»дән зачет булырга тиеш. Килдек, кереп утырдык. Укытучыбыз – Власова дигән фамилияле әйбәт кенә бер апа иде. Без инде үзебезчә зачетны бик авыр булыр дип уйладык, җитмәсә русча. Укытучы сорый башлаганчы дип, дәреслектән укып, карап утырабыз. Апабыз керде дә: «Соберите книжки»,– ди. Без инде зачет шулай авыр була икән дия-дия, өстәл өстендә булган китап-дәфтәрләребезне җыя башладык. Парта өстендә бернәрсә дә калмады. Укытучы апа безгә сәерсенеп кенә карап тордытορды да: «Я же сказала вам,соберите книжки»,– ди. Шуннан бераү, бездән өлкәнрәк, кайдадыр эшләп килгән студент бар иде. Ул безгә борылды да: «Апа бит зачеткаларны сорый,зачеткаларны»,- ди. Без шунда тиз-тиз генә зачеткаларны җыеп бирдек. Укытучыбыз студентлар телендә «автомат» дип атала торган зачетны куйды. Шулкадәр сөенә-сөенә кайтып киттек.*

*Ул вакытта инде грамоталылыгыбыз тиешле дәрәҗәдә булмаган, күрәмсең. «Соберите» белән «уберите» сүзен бутаганбыз. Рус теленең кайбер нечкәлекләренә төшенмәвебезнең бер билгесе булган инде бу...»*

**РАБОТА СТУДЕНТАМ и ДИПЛОМНИКАМ**

НПФ БЛАГОСОСТОЯНИЕ

В один из крупнейших Российских негосударственных пенсионных фондов НПФ «БЛАГОСОСТОЯНИЕ» (российские железные дороги) требуются сотрудники на должности финансового консультанта и руководителя группы.

• оформление по договору,
• гибкий график работы, возможность совмещения,
• оплата своевременная, обучение за счет компании,
• **оклад до 20 000** +премии(оклад по результатам собеседования),
Требования: аккуратность, активность, коммуникабельность, желание зарабатывать.
**Опыт работы не обязателен !!!**

**СТУДЕНТ - НЕ УПУСКАЙ ВОЗМОЖНОСТЬ - ЗАРАБОТАТЬ И ПОЛУЧИТЬ ПЕРВОНАЧАЛЬНЫЙ ОПЫТ РАБОТЫ В СВОБОДНОЕ ОТ УЧЕБЫ ВРЕМЯ!!!**

**Все подробности:**
**г.Казань, ул Московская, 31/6, офис 203**
**или по телефонам:**
**(843) 240-18-14, 259-18-89**
**http://www.vasheblagosostoyanie.ru/**

реклама

## Илһам канатында



**Зилә Алмаз кызы ГАЛИУЛЛИНА**

Быел Арча районы Яна Кенәр лицееның X сыйныфын тәгәлләде. «Нур» Арча балалар телестудиясе журналисты. Шигырьләре һәм мәкаләләре «Ялкын» журналында, «Без булдырабыз!» газетасында басыла. «Илһамлы каләм» конкурсының даими катнашучысы булган Зилә быел поэзия юнәлешендә I урынга лаек булды. Ул – Гариф Ахунов премиясе лауреаты да.

### Сиңа таба

*Кояш баешыннан сиңа таба*
*Ташлы юлдан атлап барышым.*
*Ике тамчы булган хисне барлыйм –*
*Бу хәзергә иң зур табышым.*

*Көздә күрдем сине,тик кышларга*
*Аяк бармый минем,күңел тартмый.*
*Күзләреңдәй яшел аланлыкка*
*Шуңадыр да быел кар ятмый.*

*Яфрак буранына мин төренеп,*
*Ташлы юлдан атлап барамын.*
*Син көт кенә, ә мин учларыңа*
*Көзге яңгыр булып тамармын...*

***

*Яннарыңа барыр идем очып,*
*Чыксаң әгәр каршы алырга.*
*Ә күңелем инде күптән синдә,*
*Туктаталмый кар да, яңгыр да...*

*Ә мин күптән синле төштә яшим,*
*Төннәр хыялларга үрелгән.*
*Борынгыдан калган ачы яшьләр*
*Иске яраларга түгелгән.*

*...Ә мин хыялларга күмелгән...*

### Күрешәсе килә

*Бер тын җегәр алып борылышта,*
*Ертып машиналар агымын –*
*Синең белән күрешәсем килә,*
*Күрешәсем килә...*
*Сагындым...*
*Р.Мөхәммәтшин*

*Күрешәсе килә синең белән бер мәл,*
*Әллә ничек кенә шунда, көтмәгәндә.*
*Ләса бозны ваталырлык салкын белән*
*Йөрәгемне генә минем телгәләмә!*

*Офыклардан сине эзлим бүген янә,*
*Шәфәкъ уты анык чагыла күзләремдә.*
*Тик аларның яшел төсен беркайчан да*
*Мин теләмәс идем үзгәртергә.*

*Күңел кылларымны янә бер тибрәтеп,*
*Үткәннәрне искә алган чагым әле.*
*Ике гасыр арасында бергә калсак,*
*Киләчәккә үзең белән чакыр, яме!*

*Яшел күзләр сине эзли бүген кичен,*
*Көнләшәмен син кагылган яфраклардан.*
*Ничә кичем үтә бер ышаныч белән:*
*Килеп чыксаң иде, диеп, офыклардан.*

### Янә сиңа

*Сәгать угы уникегә якынлаша,*
*Безнең күзләр кинәт кенә очраштылар...*
*Талгын бию көе уйный, күбәләк кар –*
*Көтмәгәндә биеклеккә очырдылар...*

*Карашларың фикеремне буталдырды,*
*Баш әйләнде, йөрәгемне өтә иде...*
*Бар да гади сыман, куллар гына*
*Янә кагылуны көтә инде...*

### Каршы чык

*Сагынып сиңа киләм әле менә,*
*Йөрәгемдә – хисләр бәйләме.*
*Күзләреңә бүген янә багам –*
*Көзнең тәүге... Тәүге бәйрәме.*

*Сиңа киләм менә. Сагындыңмы?*
*Ә мин исә чиксез юксынам.*
*Синсез дөнья – төсләр буталчыгы,*
*Күңелемә яшәү юк сыман.*

*Таң кояшы белән юлга чыктым,*
*Таралмаган әле көзге чык.*
*Сагынуны йөрәгемә урап*
*Килеп җиттем менә. Каршы чык.*

## Сәламәтлек

# Җәй көне суык тиде?

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Жәйге эссе көннәр... һәм каяндыр суык тидерәбез. Бер карасаң, аңлашылмый торган халәт: ничек инде эсседә суык тисен, ди? Шуңа карамастан, кондиционер-җилләткечләр белән дөрес файдаланмау, кура җиләкле чәйләрдән соң урамда йөрү, салкын су эчү үзенекен эшли, организмның хәлсезләнүен, төгәлрәк әйтсәк – суык тиюне көт тә тор шуннан соң! Ләкин кайбер кагыйдәләргә таянсаң, җылы җәйләрне дә рәхәтләнеп үткәрергә була.

Җәй ул – кояш нурларыннан иркәләнү, күптән көтелгән яллар, табигатькә ешрак чыгу һәм... ничек кенә сәер тоелмасын, озакка сузылган салкын тиюдән тиз генә арына алмау чоры. Нәкъ менә шушы сезонда без сәламәтлегебезнең ныклыгына тулысынча ышанабыз һәм саклану турында бөтенләй дә онытып җибәрәбез.

Нәтиҗәдә борынга томау төшә, туктаусыз ютәлләр, баш авыртулар берничә атнага сузыла һәм җәйнең бөтен тәмен, бөтен ямен ала.


Салкын тидерүнең иң киң таралган сәбәбе: җәйге эсселектән качу максатыннан, эш урынында яисә өйдә җилләткечләр астында яту. Моны булдырмау өчен, беренче чиратта, бүлмәдәге бөтен тәрәзә һәм ишекләрне ябарга, максималь көчкә куймыйча гына җилләткечне кабызырга кирәк. Эссе һавада озак йөргәннән соң, сусыйбыз һәм салкын суга үреләбез. Шулай итеп тавыш бетә, тамак төбендә авыртулар барлыкка килә. Тамак кибүне баса торган иң яхшы эчемлек булып яшел чәй санала. Ә туңдырмага килгәндә, аны ашарга була, ләкин аз-азлап кына.

Әгәр дә инде сезнең организмыгыз салкын тидерүче вирусларга бирешкән икән, кайбер гади генә киңәшләргә колак салырга кирәк. Тән температурасы күтәрелсә, шунда ук температура төшерә торган даруларга үрелмәгез. Бары тик ике-өч көн өйдә торуны һәм организмда С витамины тиешле дәрәҗәдә булуны тәэмин итәргә кирәк. (С витамины бик күп микъдарда лимон согында, мүк җиләгендә һәм болгар борычында бар).



Тамак төбе авыртулары үзен сиздерә башлауга, аны чайкарга кирәк, чөнки ул вакытта әле микроблар үрчергә өлгермәгән була. Сода, тоз һәм бер-ике тамчы йод кушылмасы белән тамакны чайкап җибәрү сезгә, һичшиксез, җәйге челләдә тизрәк терелергә ярдәм итәчәк. Ә бертуктаусыз дәвам иткән ютәлне дәвалау өчен, валидол кулланырга була. Билгеле, бик күп дозада түгел, ә дүрттән бер өлешен генә кабып, әкренләп кенә суырырга кирәк. Валидолдагы ментол мае каты ютәлдән бик тиз арада котылырга ярдәм итәчәк. Һәм суык тиюдән котылуның иң эффектив ысулы ул – ингаляцияләр. Ике-өч көн шушы процедураны кабатлаганнан соң, организмыбыз янәдән элеккеге «көчле» халәтенә кайтачак. Җәй бит ул авырып яту чоры түгел, ял итү, җылы һава торышыннан ләззәтләнү чоры! Шуңа күрә гади генә киңәшләргә колак салып, сау-сәламәт булып яшик!

## Дөнья үзебезнеке



# Күңелне дәвалау

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

УЛЫМ УКЫЙ ТОРГАН МӘКТӘП ДИРЕКТОРЫ ШАЛТЫРАТЫП, МИҢА БИК МӨҺИМ НӘРСӘ ХӘБӘР ИТӘРГӘ ТЕЛӘВЕН ҺӘМ КАЙЧАН КИЛЕРГӘ МӨМКИН ИКӘНЛЕКНЕ СОРАДЫ.

*Мәктәпне тәмамларга берничә генә атна калып барганлыктан,директорның шалтыратуы шушы вакыйга белән бәйледер дип уйласам да,яшүсмерлек шуклыклары өчен түгелме икән дигән сорау да эчне пошырып торды. Тик барыбер мәктәп директорының яхшы хәбәр белән килүен көттем. Яңалык, чыннан да,әйбәт булып чыкты: улым чыгарылыш кичәсендә чыгыш ясарга тиеш икән. Аның ирешкән уңышлары турында,вакыйгага туры китереп,миннән берәр нәрсә язуымны үтенде. Шатланып риза булдым. Улым һәм аның җиңүләре белән горурлана идем мин. Язарга утыргач,аның тормышын искә төшерә башладым. Шунда мин аның өчен мәктәпне тәмамлауның мәгънәсен аңладым: ул һәм классташлары күрелмәгән яңа бер дөньяга аяк басарга җыеналар. Көн дә яннарында булып,юнәлеш бирүче,кайгыртучылары булмаячак. Шуңа күрә дөньяга мин менә бу хатны яздым.*

***Кадерле дөнья!***

*Бүген безнең балаларыбыз мәктәпне тәмамлыйлар. Берара алар өчен бөтен нәрсә гадәттән тыш булачак,һәм мин синнән аларга карата хәерхаһлы булуыңны теләр идем. Беләсеңме,бүгенге көнгә кадәр алар үз гаиләләренең күз карасы кебек иделәр. Әти-әниләре аларның яраларын бәйләп, кимсетелгән хисләрен давалап,һәрвакытта да алар белән бергә иде. Хәзер бөтенесе дә башка төрле булачак. Алар яңа мажараларга таба китеп баралар. Бу мажаралар барышында,алар сугыш,трагедия,хәсрәт белән бәрелешергә мөмкиннәр. Үз юллары белән бару өчен,аларга бик күп ышаныч,мәхәббәт, түземлек һәм аңлау кирәк булачак. Шуңа күрә,дөнья,мин синең аларга күз-колак булуыңны телим. Кулларыннан тот та нәрсә белергә тиешләр – өйрәт,әмма үтенеп сорыйм,бу эшне булдыра алганча йомшаграк итеп эшләсәң иде. Аларга кешеләрнең бөтенесе дә гадел түгеллеген,бөтен кеше дә дөресен генә сөйләмәвен белергә туры киләчәк. Тик аларга тагын һәр бандитка – бер герой,күңеле чиста булмаган һәр сәясәтчегә бер бөек һәм тугрылыклы лидер,һәр дошманга бер яхшы дус булуын да өйрәт. Моңа вакыт кирәк булачак,дөнья, эшләп тапкан акчаның,табылган доллардан кыйммәте бик зур булуын да өйрәт син аларга. Җиңүнең түбән күбрәк тояр өчен,дәрәҗәңне югалтмыйча җиңелергә өйрәт. Булдыра алсаң,аларны көнчеләрдән киртәләп куй һәм әкрен генә көлү серен бүләк ит. Аллаһы Тәгалә белән тынычлыкта яшәргә булыш. Аларны көчле рухлы булырга – уңышсызлыкларны үткәреп җибәрә белергә,уңышка ирешкәнчегә кадәр тырышып карау теләген сакларга да өйрәт. Йомшак күңелле кешеләр белән – йомшак,катылары белән каты булырга өйрәт. Төркем фикере белән түгел,үз фикере белән яшәргә өйрәт. Ишеткәннәрне дөреслек фильтрыннан үткәреп,кешеләрнең барысын да тыңлый белергә өйрәт. Сагышлы минутларда көлергә өйрәт,шулай ук елауның да оят түгеллегенә өйрәт. Акылың һәм көчеңне булдыра алганча кыйбат бәягә сатарга мөмкин,ә йөрәк һәм җаныңны беркайчан да сатарга ярамаганны аңлат. Булдыра алсаң,үзләрен башкалар белән чагыштырмаска өйрәт. Аның урынына үз мөмкинлекләрен уза белергә өйрәт.*

*Дөнья,син аларга сак мөрәҗәгать ит,тик бала караган кебек түгел,утта чыныгу аркасында гына иң яхшы корыч барлыкка килә бит. Аларны үзләренә ышанырга өйрәт,һәм шунда гына алар кешелеккә ышаначаклар.*

*Бу бик катлаулы заказ,дөнья,тик башкарырга тырыш инде. Алар искиткеч яшь кешеләр – безнең балаларыбыз.*

*(Эврил Йоханнестан хезмәтеннән)*




DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.